# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# БИШНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

2023 елның 09 марты №130

Бишнә авыл җирлеге Советының 05.03.2021 елгы №32 карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (Бишнә авыл җирлеге Советының 18.08.2021 елгы №53, 20.12.2021 елгы №65 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 24 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы рәвештә, Бишнә авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Бишнә авыл җирлеге Советының 05.03.2021 елгы 32 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә (Бишнә авыл җирлеге Советының 18.08.2021 ел, №53, 20.12.2021 ел, №65 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән ) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 статьяның 2 өлеше 2 пунктының б пунктчасында "Президент" сүзен «Башлык (Раис)» сүзләре белән алыштырырга;

1.2. 5 статьяны түбәндәге эчтәлектәге 1.1 өлеш белән тулыландырырга: «1.1. Район Советы депутатының вәкаләтләре, әгәр депутат җитди сәбәпләрсез алты ай рәттән җирлек Советының барлык утырышларында булмаса, җирлек Советы карары белән вакытыннан алда туктатыла.»;

1.3. 5 статьяның 4 өлешендә "Президент" сүзен «Башлык (Раис)» сүзләре белән алыштырырга;

1.4. 12 нче маддәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"12 нче маддә. Депутатның, аның хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында мәгълүмат.

1. Әгәр федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса, муниципаль вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук үз хатыннарының (ирләренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Татарстан Республикасы Башлыгына (Раисенә) Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә мәгълүмат бирәләр.

2. Үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыручы җирлек Советы депутатлары депутат итеп сайланганнан соң, аңа вакантлы депутат мандаты тапшырылганнан соң дүрт ай дәвамында керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүмат бирә.

3. «Дәүләт Вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында»гы 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган очракларда үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыручы җирлек Советы депутатлары Россия Федерациясе законнары нигезендә керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүмат бирә.

Үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыручы җирлек Советы депутаты хисап чоры дәвамында «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында»гы 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (тормыш иптәшенең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып киткән килешүләр эшләнмәгән очракта, бу хакта Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы башлыгына (Раисенә) хәбәр итә.

4. Җирлек Советы депутатлары тапшыра торган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы мәгълүматларга, җирлек Советы депутатларының керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белә торып дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматлар тапшыру турындагы мәгълүматка керүне тәэмин итү федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты Указлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

5. Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә җирлек Советы депутатларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү бурычы үтәлеше (тиешенчә үтәлмәве) турында гомумиләштерелгән мәгълүмат Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла (мондый мәгълүматта тиешле затны идентификацияләргә мөмкинлек бирүче персональ

мәгълүматлар һәм тиешле затныкы булган мөлкәтне индивидуальләштерергә мөмкинлек бирүче мәгълүматлар булмаганда).

2. 1.2 пунктының гамәлдә булуы 01.03.2023 елдан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) халыкка игълан итәргә, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталына Интернет челтәрендә (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Бишнә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Бишнә авылы, Үзәк урамы, 5 (Советның административ бинасы), Бишнә авылы, Школьная урамы, 10 (Бишнә авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерен торуны Бишнә авыл җирлеге Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Бишнә авыл җирлеге**
**башлыгы, Совет рәисе:** **И.М.Фатхуллин**